*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2021-2022 нче уку елы)
**11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 52**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Җөмләдәге ачык иҗекләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Үз илең – алтын бишек.* (Мәкаль)
а) 1;
**ә) 2;**
б) 3;
в) 4.

2. Бирелгән фразеологик әйтелмәнең мәгънәсе дөрес аңлатылган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Тишек көймәгә утырту*
а) *суда бату*;
ә) *йөзә белмәү*;
**б) *алдалау*;**
в) *ачулану*.

3. Сыйфат ясагыч кушымчаларны билгеләгез. **(2 балл)**

а) -ча/-чә, -лап/-ләп;
ә) -ла/-лә, -лаш/-ләш;
**б) -лы/-ле, -чан/-чән;**
в) -чы/-че, -даш/-дәш.

4. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Эше барның ашы **бар**.* (Мәкаль)
а) фигыль;
ә) бәйлек;
б) теркәгеч;
**в) хәбәрлек сүз.**

5. Җөмләдәге затланышсыз фигыль күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Карама кешенең йөзенә, кара әйткән сүзенә.* (Мәкаль)

а) *карама;*
ә) *кара;*
б) *йөзенә;*
**в) *әйткән.***

6. Җөмләнең иясе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
*Куркак аулакта батыр була.* (Мәкаль)
**а) *куркак*;**
ә) *аулакта*;
б) *батыр*;
в) *була*.

7. Җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
*Төн кара булган саен, йолдыз яктырак яна.* (Мәкаль)
а) гади җөмлә;
ә) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә;
б) теркәгечле тезмә кушма җөмлә;
**в) иярченле кушма җөмлә.**

8. Җөмләдәге иярчен компонентның мәгънә ягыннан төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
*Үзең кабалансаң, атың да абына.* (Мәкаль)
а) иярчен кире шарт җөмлә;
**ә) иярчен шарт җөмлә;**
б) иярчен вакыт җөмлә;
в) иярчен тәмамлык җөмлә.

## II. Теоретик бирем.

Күпнокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(8 балл)**

*Татар телендә о, ө хәрефләре сүзнең* ***беренче*** *иҗегендә генә языла. Язылышлары төрле, әйтелешләре бертөрле булган сүзләр* ***омофон*** *дип атала.* ***Кыскартылма*** *сүзләр тезмә сүзләрне кыскарту юлы белән ясала. Зат-сан белән төрләнми торган фигыльләр* ***затланышсыз*** *фигыльләр дип атала.* ***Бүлем*** *саны предметларның яисә затларның тигез өлешләргә бүленүен белдерә. Аергыч –* ***исемгә****, ә тәмамлык фигыльгә ияртә.* ***Инкяр*** *җөмлә нәрсәне дә булса инкяр итә. Иярчен* ***сәбәп*** *җөмлә баш җөмләнең сәбәп хәле урынында килә.*

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итегез. **(16 балл)**

*Однажды отец принёс пучок зелёных прутиков и сказал:*

- *Это смородиновые черенки. Будем смородину сажать.*

*Стала Таня разглядывать черенки. Палочки как палочки – чуть длиннее карандаша. Удивилась Таня:*

- *Как же из этих палочек вырастет смородина, когда у них нет ни корешков, ни веточек?*

*А отец отвечает:*

- *Зато на них почки есть. Из нижних почек пойдут корешки. А вот из этой, верхней, вырастет смородиновый куст.*

*Не верилось Тане, что маленькая почка может стать большим кустом. Сама решила перед избой посадить и вырастить смородину. А там лопухи с репейником росли. Повыдергала она их и принялась землю вскапывать. Нелёгкая это работа.*

2. Көз көне бакчада нинди эшләр башкаралар? Шул хакта фикерләрегезне 12 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. **(12 балл)**